ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино,
Арский муниципальный район,
422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле
авылы, Арча муниципаль районы,
422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail:
Schur.Ars@tatar.ru.

**КАРАР**

**18.07.2016 ел** **№ 12**

**Иске Чүриле авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында” Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге административ регламентларын расларга:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1нче кушымта).

1.2. Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашлауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Васыятьләр һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр һәм зур габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).
1.8. Күченеп килергә мәҗбүр булганнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм торак сатып алуга субсидияләр бирү өчен дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).
1.9. Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм дәүләт торак сертификатын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).
1.10. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарын муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).
2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 14 июнендәге 8 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина